РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ МОРДОВСКО-АФОНЬКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
423103, Мордовское Афонькино село, Цаплина ул., 19 дом

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**МОРДВА АФОНЬКӘСЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
423103, Мордва Афонькәсе авылы, Цаплин урамы, 19нчы йорт

тел. (84396) 3-48-29, факс: (84396) 3-48-49, email: Mord.Cmn2@tatar.ru

№ 108 23.10.2023 ел

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советының «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2023 елның 7 июнендәге № 95 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Мордва Афонькәсе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2023 елның 7 июнендәге № 95 ТР Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советы карарының 1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге пунктчалар белән тулыландырырга:

4) «Башкарма производство турында» 2007 елның 2 октябрендәге № 229-ФЗ Федераль законның 46 һәм 47 статьяларының 1 өлешендәге 3,4 пунктларына ярашлы рәвештә башкарма производствоны тәмамлау турында суд приставы тарафыннан карар чыгару;

5) салым түләүче физик затның гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада булуы (өлкәннәр, инвалидлар, яшь

инвалидлар, инвалид балалар, сугыш һәм хезмәт ветераннары өчен интернат - йортларда;

- интернат-йортларда, шул исәптән психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар йортларында;

- махсус интернат-йортларда, шул исәптән картлар һәм башкалар өчен) җирле үзидарә органнары тәкъдим иткән документлар нигезендә;

6) ата-аналары ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән балалар йортларында һәм приютта тәрбияләнүче балигъ булмаган физик затлар;

7) җирле үзидарә органнарының раслаучы документлары булган очракта аз керемле физик затлар;

8) психик тайпылышлары булган, суд карары яки җирле үзидарә органнары тәкъдим иткән документлар нигезендә суд тәртибендә эшкә сәләтсез дип танылган физик затлар;

9) ирегеннән мәхрүм итү урыннарында булган физик затлар, - суд карары нигезендә иректән мәхрүм итү урыннарында булу чорына.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Мордва Афонькәсе авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе А.И.Митяев